БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«19» 10 2023 ел

**КАРАР**

№ 265

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы милкендә булган һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары сатып ала торган арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне арендага алган өчен түләүне кичектереп тору срогын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы, «Дәүләт милкендә яисә муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1.«Дәүләт милкендә яисә муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы милкендәге һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары сатып ала торган арендалана торган мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда арендалана торган милек өчен кичектереп түләү вакыты күчемсез мөлкәт өчен сигез ел һәм күчемле мөлкәт өчен өч ел тәшкил итә.

2. Арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәткә түләү тәртибен (бер үк вакытта яисә кичектереп) сайлау хокукы, шулай ук әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнгән кысаларда өлешләп түләү сроклары арендалана торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече яисә урта эшмәкәрлек субъектына карый.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач

муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi. tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4.Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
Җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов